**РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, 3-44-14, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
17.05.2019

КАРАР
ПР-112

**РФ КоАП 20.25 ст. 1 өлешендә каралган административ хокук бозу турында беркетмә төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затларны билгеләү турында**

РФ административ хокук бозулар турындагы кодекснның 20.25 матдәләре нигезендә, "Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында "1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 30.12.2005 елдагы 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.25 статьясындагы 1 өлешендә каралган административ хокук бозу турында беркетмә төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затларны билгеләп куярга:

1.1. Мирзаянова Алисә Рафисовна – Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясе җаваплы секретаре, баш белгеч;

1.2. Хаҗиева Земфира Мөдәрис кызы-Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясе баш белгече.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи затларга тиешле административ хокук бозуларны ачыклау, кисәтү һәм бетерү буенча чаралар күрергә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Руководитель
исполнительного комитета — И. Ш. Бариев